ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**17.06.2020**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 1102**

«Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 16 мартындагы «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршында Икътисадый Совет төзү турында» 502 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Икътисадый совет турында Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (2020 елның 30 мартындагы 621 номерлы үзгәрешләре белән)

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 16 мартындагы «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршында Икътисадый совет төзү турында» 502 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршында Икътисади Совет турындагы Нигезләмәне гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршында Икътисадый совет төзү турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 16 мартындагы «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршында Икътисадый совет төзү турында» 502 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисадый советы турында Нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (1нче кушымта).
2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 16 мартындагы «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршында Икътисадый совет төзү турында» 502 номерлы карарының 3 пунктын үз көчен югалткан дип таныырга.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (www.zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкченең беренче урынбасары А.В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
1 нче кушымта
_______________ № _____________

**Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының Икътисадый советы турында
НИГЕЗЛӘМӘ**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының Икътисадый советы (алга таба – Икътисадый совет) Зеленодольск муниципаль районы предприятиеләре һәм оешмалары эшчәнлеген тотрыклыландыру, финанс-кредит секторын савыктыру, халыкка социаль һәм икътисадый ярдәм күрсәтү чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләрне оператив хәл итү максатыннан оештырылган киңәшмә органы булып тора.

2. Икътисадый совет үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты һәм Татарстан Республикасы Президенты Указларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, Зеленодольск муниципаль районының норматив-хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Икътисади советның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- социаль-икътисадый өлкәдә кризис күренешләрен булдырмау, аның алга таба үсешен һәм тотрыклылыгын тәэмин итү механизмнарын эшләү һәм тормышка ашыру;

-сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләре, Зеленодольск муниципаль районы икътисадының реаль секторындагы башка оешмалар эшчәнлеген тотрыкландыру, финанс-кредит секторын савыктыру, халыкка социаль һәм икътисадый ярдәм күрсәтү чараларын тормышка ашыруга даими мониторинг;

4. Икътисадый совет турында Нигезләмә һәм аның составы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

Икътисадый совет составына Икътисадый совет рәисе, аның урынбасары, секретаре һәм Икътисадый совет әгъзалары керә.

Икътисади совет әгъзалары аның эшендә җәмәгать башлангычларында катнаша. Икътисади совет әгъзалары саны 15 кешедән дә ким булмаска тиеш.

5. Икътисадый совет үзенең төп бурычларын үтәү өчен түбәндәгеләргә хокуклы:

- җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт һәм федераль хакимият органнарыннан, иҗтимагый берләшмәләрдән, предприятиеләр һәм оешмалардан, фәнни һәм башка оешмалардан, шулай ук вазыйфаи затлардан тиешле тәртиптә кирәкле материалларны соратып алдырырга һәм алырга;

- үз утырышларына җирле үзидарә органнарының, дәүләт һәм федераль хакимият органнарының вазыйфаи затларын, иҗтимагый берләшмәләрнең, фәнни һәм башка оешмаларның вәкилләрен чакырырга;

- мәгълүмати-аналитик һәм эксперт эшләрен гамәлгә ашыру өчен фәнни һәм башка оешмаларны билгеләнгән тәртиптә җәлеп итәргә.

6. Икътисадый совет утырышлары кварталга кимендә бер тапкыр уздырыла. Кирәк булган очракта, Икътисадый советның чираттан тыш утырышлары үткәрелә.

7. Икътисадый совет утырышын Икътисадый совет рәисе алып бара. Рәис булмаганда, аның вазифаларын урынбасары башкара.

Утырыш, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

Икътисадый совет карарлары рәислек итүче тарафыннан 5 эш көне дәвамында раслана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

Икътисадый совет карарларын тормышка ашыру өчен Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары һәм боерыклары чыгарылырга мөмкин.

8. Комиссия рәисе:

аның эшчәнлеге белән җитәкчелек итә;

Комиссия әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә, Комиссия утырышларын үткәрә һәм аларга рәислек итә;

Комиссия эшчәнлеген тәэмин итә торган карарлар кабул итә.

9. Комиссия рәисе урынбасары:

Комиссия рәисе булмаганда , аның вазыйфаларын башкара; Комиссия рәисе күрсәтмәләрен үти.

10. Комиссия секретаре:

Комиссия рәисе йөкләмәләрен үти;

Комиссия эшен оештыру-техник яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

Комиссия утырышлары беркетмәсен алып бара.

11. Комиссия әгъзалары Комиссия утырышы көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча фикер алышканда тигез хокукларга ия һәм түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

Комиссия утырышларында катнашалар;

карау өчен чыгарылган мәсьәләләр буенча материаллар белән алдан танышалар;

Комиссиягә йөкләнгән бурычларны тормышка ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертәләр;

Комиссия рәисе тарафыннан билгеләнгән срокка утырышның көн тәртибе мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр җибәрәләр;

Комиссия тарафыннан кабул ителгән карарлар буенча фикер алышуда катнашалар һәм аларны кабул иткәндә тавыш бирәләр;

Комиссия рәисе һәм аның урынбасары йөкләмәләрен үтиләр.

12. Икътисадый совет карарлары үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районының структур бүлекчәләре үз вәкаләтләре нигезендә гамәлгә ашыра.